| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2021 с.Старое Дрожжаное №616

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә урнашкан мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) терроризмга каршы якланганлыгын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү хакының нормативларын раслау һәм 12 сәгатьлек эш режимы белән сакчылык постлары санын билгеләү турында

«Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законның $5^1$ статьясындагы 2 өлешенең 7 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 24 ноябрендәге 1114 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә урнашкан мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү бәясенең нормативларын (алга таба - мәгариф оешмасы) расларга:

беренче хәвефлелек категориясендәге мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен - бер сакчылык постына сәгатенә 150 сум күләмендә;

икенче хәвефлелек категориясендәге мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен - бер сакчылык постына сәгатенә 150 сум күләмендә;

өченче хәвефлелек категориядәге мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен - бер сакчылык постына сәгатенә 130 сум күләмендә.

2. Бер мәгариф оешмасында 12 сәгатьлек эш режимы белән сакчылык постлары санын билгеләргә:

беренче хәвефлелек категориядәге мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен - 2 сакчылык посты;

икенче хәвефлелек категорияле мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен -1 сакчылык посты;

өченче хәвефлелек категорияле мәгариф оешмалары объектлары (территорияләре) өчен - 1 сакчылык посты.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ф. Җәләловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов